ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында” Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында” 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш); 2013, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) 6 пунктта “Россия Федерациясе гражданлыгы” сүзләре алдыннан “җәмәгатьчелек вәкиленең” сүзләрен өстәргә;

б) 7 пунктта “җәмәгатьчелек вәкиленә карата” сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 11 һәм 12 пунктлар өстәргә:

“11) Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе утырышларында җәмәгатьчелек вәкиленең нигезле сәбәпләрсез дүрт ай дәвамында булмавы;

12) җәмәгатьчелек вәкиленең үз абруена тап төшерә торган гамәл кылуы.”;

2) $1^1$ өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 68-ТРЗ